РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423646 Республика Татарстан, Менделеевский район, д.Псеево
ул. Центральная, д.4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

423646 Татарстан Республикасы, Менделеевск районы,
Песәй авылы, Үзәк урам,4 йорт

Тел. (факс): (85549) 3-71-22 e-mail: Psv.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 ноябрь 2019 ел № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча
Менделеевск муниципаль районының
Песәй авыл җирлегенең
Тукай авылында гражданнар җыенын
билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының муниципаль берәмлеге Песәй авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 29 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2019 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I һәм II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылар, тәрбияләрендә балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләр, көндезге (көндезге бүлек) уку формалары студентлары өчен, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнарга бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм әлеге категория гражданнар өчен 150 сум күләмендә билгеләргә, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1) Юлларны кардан чистарту
2) Вак таш сатып алу
3) Вак таш тигезләү

ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Песәй авыл җирлеге» бүлегендә кабул ителгән көннән 3 көн эчендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Песәй авыл җирлеге башлыгы Мөхәммәтгалиев В. И.